# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

14 ноябрь 2024 ел. № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының "Вәрәшбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2024 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз сум) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле сум) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә ризамы:

1). **Торак пункт территориясен төзекләндерү**:

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы кору;
- төзелеш материаллары сатып алу һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү;
- үлән чабу;

**2). Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу, урнаштыру;

**3). Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су башнясын караучыга хезмәтләре өчен килешү буенча түләү;
- су башнясына хезмәт күрсәтү;
- анализга су алу .

**4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

**5). Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү , ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- Бөек Ватан сугышы ветераннары истәлегенә куелган һәйкәлне төзекләндерү.

**6). Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- җәйге чорда юл буйларындагы үләннәрне чабу( ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы);

- авыл эчендәге урам юлларын кышкы һәм җәйге вакытта карап тору. Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарын кардан чистарту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү,"Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);

- язгы ташу чорында торбаларны кардан чистарту.

**7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү:**

- "Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләрен төзекләндерү.

**8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар төзү:**

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;
- койма буяу;
- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, , килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- карт агачларны кисү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 154 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 82, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 81 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 1 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең Вәрәшбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

**1). Торак пункт территориясен төзекләндерү.**

- Кооператив урамында спорт мәйданчыгы кору;
- төзелеш материаллары сатып алу һәм халыкның күплэп ял итү урыннарын төзекләндерү;
- үлән чабу;

**2). Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Беренче Май, Кооператив һәм Комсомол урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу, урнаштыру;

3). **Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су башнясын караучыга хезмәтләре өчен килешү буенча түләү;
- су башнясына хезмәт күрсәтү;
- анализга су алу .

**4). Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

**5). Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзекләндерү , ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү**:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары истәлегенә куелган һәйкәлне төзекләндерү.

**6). Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- җәйге чорда юл буйларындагы үләннәрне чабу( ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы);
- авыл эчендәге урам юлларын кышкы һәм җәйге вакытта карап тору. Беренче Май, Кооператив, Комсомол урамнарын кардан чистарту(штаттан тыш хезмәткәргә (тракторчыга) хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары өчен түләү,"Беларус " тракторы өчен запас частьләр һәм өстәмә җиһазлар сатып алу);
- язгы ташу чорында торбаларны кардан чистарту.

**7). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү**:

- "Салкын Чишмә", "Тәпти", "Исрафил "чишмәләрен төзекләндерү.

**8). Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар төзү:**

- зираттан каты коммуналь калдыклар чыгару;
- койма буяу;
- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, , килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- карт агачларны кисү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Вәрәшбаш авылы, Кооператив урамы, 45а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмәт стендларына, Мөслим муниципаль районының Интернет мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://muslumovo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы З.З.Галиева